РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.02.2021 № 215-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 3 декабрендәге 1780-п номерлы карары белән расланган, тышкы мәгълүмат чараларын (паспорт) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеш йомгаклары һәм 2021 елга Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Тышкы мәгълүмат чараларын (паспорт) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2018 елның 3 декабрендәге 1780-п номерлы карары белән расланган, тышкы мәгълүмат чараларын (паспорт) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1**. 2.6 пунктындагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 6) пунктча өстәргә:

“6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.”;

**1.2.** 2.8 пунктындагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 5) пунктча өстәргә:

“5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.”;

**1.3.** 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5) пунктча өстәргә:

«5) законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр.”;

**2.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru _рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов